**СОВЕТ СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу. ул. Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

Тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail:Suks.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18 июль 2022 ел** **№60**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны гамәлдән чыгару хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 176 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын (Советның 07.08.2020 №191, 19.01.2021 №19 карарлары редакциясендә) федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы карар проекты турында»гы 42 нче номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Суксу авылы, Школьная урамы, 9А йорт адресы буенча «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» 26.10.2021 в10.00 сәгатьтә үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 176 номерлы карары (Советның 07.08.2020 ел, №191, 19.01.2021 ел, № 19 карары редакциясендә) белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге

«муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып, эшләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев